Республика Татарстан
Глава Тураевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423647, Менделеевский район, с. Тураево,
ул.Центральная, д 11а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге Башлыгы

423647, Менделеевск районы, Турай авылы,
Үзәк урамы, 11а

тел./факс 8/85549/2-73-31, E-mail: Tur.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/turaevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 нче елның 4 нче декабрендәге 1 нче номерлы карары

Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең Татар
Әхтиялы авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча халык
җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын 2021 нче елның 14 нче декабре 12 сәгать 00 минутта билгеләргә . Җыенны үткәрү урыны итеп Татар Әхтиялы авылы, Үзәк урам, 9 Б йорты адресы буенча урнашкан Татар Әхтиялы авылы мәдәният йортын билгеләргә

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2022 елда Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылы территориясенддә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә 1000 сум күләмендә акча билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- генератор, сугым чүкеч, чокыр тишү буры, перфоратор, Татар Әхтиялы зираты өчен җиһазлар сатып алу ;

-су башнясы территориясен төзекләндерү (агачлар кисү).

“Риза” “каршы”

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Турай авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә. www.mendeleevsk.tatar.ru
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Рәхимова А.М.